ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ УРЫССУ БИСТӘСЕ СОВЕТЫ
КАРАР № 38

Урыссу штб 12. 11. 2024 ел

«Физик затлар мөлкәтенә салым турында»гы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе Советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында»гы 12.07.2024 елның № 176-ФЗ санлы Федераль закон, «Салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып, физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын билгеләү тәртибен Татарстан Республикасы территориясендә куллана башлауның бердәм датасын билгеләү турында»гы 30.10.2014 елның № 82-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 28.07.2004 елның №45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы законы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының "шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының шәһәр тибындагы Урыссу Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында»гы 25.04.2024 елның № 5 санлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Карарның 2 пунктындагы 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларына карата Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектларына карата 2 процент;»;

1.2. 2 пунктның 3 һәм 4 подпунктларында подпункт ахырында "." тыныш билгесен «;» тыныш билгесе белән алмаштырырга;

1.3. Карарның 2 пунктына түбәндәге эчтәлекле 5 пунктча өстәргә:

"5) һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына карата 2,5 процент.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының "шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе" муниципаль берәмлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталы составында http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районының
шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе Башлыгы
урынбасары Р.М.Гарипов